РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ИЗМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422052, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Измя, ул. Школьная, 9
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЭЗМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422052, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 9 йорт
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

e-mail: Izm.sab@tatar.ru

21 ноября 2018 г. № 34

РЕШЕНИЕ КАРАР

2018 нче елның 18 нче ноябрендә узган референдумда
кабул ителгән карарны теркәү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018нче елның 19 нчы ноябрендә кабул ителгән 76/7 номерлы “2018 елның 18 ноябрендә “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге биләмәсендә узган биләмәсендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында” мөрәҗәгатен караганнан соң, Татарстан Республикасының 24.03.2004 елгы 23-ЗРТ номерлы “Җирле референдум турында” Законының 60 нчы статьясы, 3 нче пунктына, Эзмә авыл җирлеге Советының 2014нче елның 12 нче маенда кабул ителгән 16 нчы номерлы “Эзмә авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы, аны җыю һәм куллану турында Нигезләмәне раслау турында” карарына, “ Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Уставына, Эзмә авыл җирлеге Советының 2016нчы елның 12 нче декабрендә кабул ителгән 34 нче номерлы “ Эзмә авыл җирлеге биләмәсендә гражданнарның үзара салым акчасы, аны җыю һәм куллану турында Нигезләмәне раслау турында карарына үзгәрешләр кертү турында” карарына таянып, 2018нче елның 18нче ноябрендә булып узган референдумда гаржданнарның “Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Эзмә авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Пүкәл авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Өтернәс авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Олыяз авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Олыяз авылында күмү урыннарын карап тоту;
- Иләбәр авылында чишмә һәм чишмә тирәсен төзекләндерү;
- Иләбәр авылында Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәйкәл төзү һәм карап тоту.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Саба районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 нче елның 19 нчы ноябрендә кабул ителгән 76/7 нче карарын теркәргә

2. 2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/ Эзмә авыл

җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: https://saby.tatar.ru/izma Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында адреслар урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: - Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 9; - Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 5а; - Олыяз авылы, Ленин урамы, 18.

3. 3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Эзмә авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Эзмә авыл җирлеге башлыгы А.Р.Шайхетдинов